КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 22 март г.Казань № б-711

Хезмәтне саклау мәсьәләләренә җәмәгатьчелек игътибарын җәлеп итү, производствода бәхетсезлек очракларын һәм һөнәри авыруларны булдырмау, шулай ук эшчәнлекнең барлык өлкәләренә хезмәт культурасын кертү максатларында:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 1 апреленнән 1 июненә кадәр Бөтендөнья хезмәтне саклау көненә багышланган чараларны үткәрү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә – гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә: Бөтендөнья хезмәтне саклау көненә багышланган чараларны, шул исәптән, эш бирүчеләрне һәм хезмәткәрләрне җәлеп итеп, хезмәткәрләргә эшләр башкаруның куркынычсыз алымнарын өйрәтүне оештыру, хезмәтне саклау һәм хезмәтне саклау кагыйдәләрен һәм нормаларын үтәү өлкәсендә бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча форумнар, Хезмәтне саклау көннәрен, «түгәрәк өстәл» утырышларын, киңәшмәләр, смотр-конкурсларын үткәрү чараларын тормышка ашыруда актив катнашуны.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына бу боерыкның 2 пунктында күрсәтелгән чараларны 2023 елга Татарстан Республикасы бюджетында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән тиешле баш эш итүчеләргә каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырырга.

4. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Бөтендөнья хезмәтне саклау көненә багышланган чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртуны оештырырга.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин